| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 21 июле № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының “Глазово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләү, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 9 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләү, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 9 мартындагы 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1 Кулланучыларга терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән хәбәр итү.».

2.Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы,_Үрнәк-Күмәк ав., Мәктәп ур., 3а й.; Глазово ав., Заречная ур., 13 й.; Петропавловка ав., Горький ур., 19а йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә , Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан

Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы — Н.К.Карабаева